**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**17.10.2022г.** **№ 63**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 30 апрелендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Татарстан Республикасында үз вәкәләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында" 22.08.2022 ел, № 881 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 30.04.2018 ел, № 122 карары (204.09.2018 № 145, 16.01.2019 № 159, 30.09.2020 № 6 карарының редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә вазыйфаи затларның алар биләгән муниципаль хезмәт вазифаларына ярашлы рәвештә Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан

Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 30.04.2018 ел, № 122 карары (204.09.2018 № 145, 16.01.2019 № 159, 30.09.2020 № 6 карарының редакциясендә) белән расланган тәртиптә вазыйфа окладларын арттырырга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа окладың күләмен 1,04 тапкыр индексацияләү һәм аны 11958 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының, муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 30.04.2018 ел, № 122 карары (20.09.2018 ел, № 145, 16.01.2019 № 159, 30.09.2020 № 6 редакциясендә) белән расланган 2 нче кушымта таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләүләре күләме»

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы | 16389 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән, рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина